ГЛАВА ЧУКМАРЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЬ САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЧУКМАРЛЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**2025 ел, 7 ноябрь** **№ 5**

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Чукмарлы авыл җирлегенең Нарат-Асты авылы гражданнарынын үзара салым акчаларын кертү җыенын билгеләү турында һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында

«Иҗтимагый хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Сарман муниципаль районының Чукмарлы авыл җирлеге Уставының 18.1 маддәсенә таянып, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы «Чукмарлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы карар кабул итте:

1. 2025 елның 19 ноябрендә 13.00 сәгатькә Сарман муниципаль районы, Нарат - Асты авылы, Нарат Асты урамы, 23 нче йорт адресы буенча урнашкан Нарат - Асты авылы медпункты бинасында, Сарман муниципаль районы Чукмарлы авыл җирлегенең Нарат-Асты торак пунктында 2026 елда гражданнарга үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

“Сез 2026 елда яшэу урыны буенча теркэлгэн һәр балигъ булган кешедэн 20300 кулэмендэ узара салым кертергэ ризамы? Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Чукмарлы авыл җирлегенен Нарат – Асты авылында I төркем инвалидлардан, хэрби хезмәт үтүче гражданнардан, көндезге уку йортлары студентларыннан, махсус хэрби операциядә катнашучылардан алынган акчалар җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгэ юнэлтелеп баручы, түбәндәге эшләрне башкару буенча:

1) электр челтәрләренең тышкы яктыртуын ремонтлау, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм аларга якын урнашкан мәйданчыкларны, бүлү

пунктларын һәм электр элемтәсен тәэмин итү өчен билгеләнгән башка мәйданчыкларны ремонтлау һәм торак пунктларга электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру (лампалар, энергияне саклый торган яктырткычлар сатып алу һәм урнаштыру, шартнамә буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

2 ) торак пунктлар чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Нарат- Асты торак пунктында территорияне кардан чистарту, шартнамә буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү)

3) Нарат- Асты торак пункты территориясен төзекләндерү (триммер, триммер өчен ягулык-майлау материаллары сатып алу).

4) ремонт, киртәләр кору, традицион күмү урыннарын төзекләндерү (Нарат Асты зираты өчен профиль һәм калай сатып алу)

«ЭЙЕ» «Юк»?

3. «Сарман муниципаль районының Чукмарлы авыл җирлеге башлыгы карары «2026 елда гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Сарман муниципаль районының Чукмарлы авыл җирлегендә гражданнар җыенын билгеләү турында» 01.11.2025елдагы 3 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

4 .Әлеге карарны 7 көн эчендә «Сарман муниципаль районы», муниципаль берэмлекнен рэсми сайтына, «Интернет мәгълүмат» теле коммуникация челтэрендэ, Чукмарлы жирлеге стендларында урнаштыру юлы белән халыкка житкерергә.

5. Әлеге карар игълан ителгэн көннән үз көченә керә.

Чукмарлы авыл җирлеге башлыгы
Сарман муниципаль районы И. Н.Хадиуллин